# Башлангыч класс укытучылары өчен

Тема:Укыту-тәрбия эшчәнлегендә яңа информацион һәм коммуникатив технологияләр куллану

# Тема : «Башлангыч мәктәптә проект эшчәнлеге”

Башлангыч класс укытучыларының район семинары

# Проект эшчәнлеген ничек оештырырга?

| Укытучы | Укучы | Ата-ана |
| --- | --- | --- |
| Киңәшче | идеяне | кирәкле |
| | тормышка | мәгълүматны |
| Рухландыручы | ашыручы | табарга |
| Илһам өстәүче | | ярдәм |
| Юнәлеш бирүче | | итүче |


- Укытучы эш барышында балаларга киңәшләр бирә,мәгълүмат җыярга, тәҗрибә үткәрергә өйрәтү максатыннын консультацияләр бирә.



# Проект эшчәнлегенең этаплары:

1) проектның проблемасы яки идея барлыкка килү;
2) темасын уйлап табу;
3) максатын һәм бурычларын билгеләү;
4) гипотеза;
5) планын төзү;
6) проект эшенең күрсәткече;
7) нәтиҗә.

- Проект эшчәнлеген башкарганда иң элек проблема, ягъни идея барлыкка килә, аннан соң гына тема билгеләнә.



# Проектның темасы

- Бу этапта ни өчен нәкъ менә бу тема сайлануына басым ясала.
- Мәсәлән, 2 класс укучылары белән без ” Сәнгать әсәрләрендә куян образы” темасын сайладык.Проект эшчәнлеге барышында матур әдәбиятта, җыр сәнгатендә, сынлы сәнгатьтә акыллы, куркак куяннар турында нинди әсәрләр иҗат ителгәнен өйрәндек.

# Проектның максаты

- Проектның нинди максаттан чыгып башкарылуын аңлату белән беррәттән, әлеге проект эшенең ни дәрәҗәдә актуаль, нәрсәгә нигезләнгән булуын да ассызыклап үтәргә кирәк.

# Проектның бурычларлары

Проектка берничә бурыч куела:

- теория белән бәйле бурычлар ( яңа мәгълүматлар өйрәнү, табу, җыю);
- өйрәнү объекты буенча тәҗрибәләр, эзләнү-тикшеренү эшләре үткәрү, объектны модельләштерү бурычлары;
- презентация белән бәйле бурычлар (проектны яклау).

# Проектның планы

Проектның максатын,бурычларын ачыклаганнан соң, эшнең гамәли өлешенә керешкәнче,укучыларны эш барышында кулланылачак алым, ысуллар белән таныштырырга, аңлатмалар бирергә кирәк. Моңа түбәндәгеләр кирә:

- китап уку;
- мәгълүмат туплау;
- өлкәннәрдән сораштыру;
- күзәтү;
- тәҗрибә үткәрү;
-мөстәкыйль уйлау;
- интернет мәгълүматларын файдалану, һ.б.

Проектны яклаган вакытта исә кулланылган эш алымнары,ысуллары белән бурычлар арасындагы үзара бәйләнешне аңлатып,әлеге алым, ысулларның бурычларны тормышка ашыруда ярдәм итүен исбатлап күрсәтергә кирәк.Мәсәлән, бала болай сөйләргә мөмкин:”Мәгълүмат җыю өчен

(бу теоретик бурыч) без өлкәннәрдән:әби-бабайдан,әти-әни, күршеләрдән сораштык;энциклопедик һәм әдәби китаплар укыдык;Интернет мәгълүматлары белән таныштык;белгеч

белән киңәшләштек».

Балалар объектны модельләштерү, эзләнү-тикшеренү бурычларын тормышка ашырганда үткәргән тәҗрибәләре,иҗади эшләре турында сөйлиләр.Тәҗрибәнең нәтиҗәсе хакында бик төгәл итеп сөйләү, модельләштерүнең кирәклелеген дәлилләп күрсәтә алу аеруча мөһим.

# Проект эшенең күрсәткече(продукт)

Һәрбер проект эше ахырында күрсәткечнең  презентациясе үткәрелә. Балалар эшчәнлегенең күрсәткече- объектның моделе, инша,рәсем, шигырь,табышмак һ.б. була ала.Аны тәкъдим итү укучы өчен аеруча файдалы һәм әһәмиятле. Проектның идеясен,максат һәм бурычларын тормышка ашыру барышында башкарылган иҗади эш күрсәткечендә

проект эшчәнлегенең нәтиҗәсе итеп мәгълүматлар тупланган кечкенә китап яисә сценарий, каталог, фильм һ.б. әзерләргә мөмкин.

